| | 7.Сыйфат.<br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>8.Алмашлык. | | итү.<br><br>* Сыйфатның мәгънәсе, сораулары. Асыл сыйфатларны үзләштерүгә хәзерлек максатыннан, аларның зат яки предметның төсен (*ак, кара*), тәмен (*тәмле, татлы*), формасын (*яссы, очлы*), массасын (*авыр, җиңел*), күләмен (*зур, кечкенә*), холкын (*юаш, усал*) белдерүчеләре исәбенә сүз байлыгын арттыру. Сыйфатларны шуңа карап төркемләү, һәр төркемгә яңа сүзләр өстәү. Сыйфат дәрәҗәләре: төп, чагыштыру, артыклык, кимлек дәрәҗәләре. Сыйфат дәрәҗәләренең ясалышы, аларның дөрес язылышы. Сыйфатның җөмләдәге исемне ачыклап килүе, аның төрләнмәве. Сыйфатларның сөйләмдәге әһәмияте. Җөмләдә сыйфатның аергыч, хәбәр функцияләрендә килүләренә гамәли күзәтүләр. Тасвирлама тибындагы текстларда сыйфатларны төгәл һәм урынлы куллану. Антоним һәм синоним сыйфатлар исәбенә сөйләмне төгәлләндерү, баету.<br><br>* Алмашлыкларның мәгънә үзенчәлегенә — зат һәм предметны атамыйча, исемен генә алмаштырып килүенә күзәтүләр. Грамматик төшенчәнең (*алмашлык*) атамасын, аның составына мөрәҗәгать итеп, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 9.Кисәкчә. | | аңлату.<br>Зат алмашлыклары. Аларның җөмләләрне бер-берсенә бәйләүдәге роле. 1 нче, 2 нче, 3 нче зат алмашлыкларын сөйләшүдә катнашучыларга мөнәсәбәтле рәвештә төркемләү: 1 нче зат — сөйләүче үзе, 2 нче зат — әңгәмәдәш, 3 нче зат — әңгәмәдә катнашмаучы. Алмашлыкларның берлек/күплек формалары, килеш һәм тартым белән төрләнүе.<br>Сорау алмашлыклары. *Кем?* соравын затка-кешегә карата гына куллану. Сорау алмашлыкларында сүз басымының урынын истә калдыру һәм сөйләмдә дөрес куллану.<br>Алмашлыкларны, җөмләләрне бәйләүче чара итеп, сөйләмдә гамәли куллану.<br><br>**да/дә, та/тә, гына/генә, кына/кенә, ук/үк, ич, бит* кисәкчәләре. Аларның сөйләмдәге роле, аерым сүз булуы, сүз басымын үзләренә алмавы. Өйрәнелгән сүз төркемнәре белән кисәкчәләрнең кулланышы һәм дөрес язылышы. Сүз басымын кисәкчәләрне дөрес язуда файдалану (бакча*да*, бак*ча* да).<br><br>* Төрле килешләрдә исемнәрнең һәм зат алмашлыкларының *белән, саен,* |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 10.Бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр.<br><br>11.Синтаксис<br><br>12.Сүзтезмә<br><br>13.Текст. Бәйләнешле сөйләм. | | *шикелле, өчен, аркылы, таба,хәтле, каршы, кадәр, чаклы, бирле, соң, башка* бәйлекләре белән килүе.<br><br>* Җөмләнең әйтелү максаты буенча төрләре (хикәя, сорау, өндәү). Тойгылы җөмләләр. Шул төрләргә карап, җөмлә ахырына тыныш билгесе кую. Җөмләнең баш кисәкләре. Гадәти язма сөйләмдә ия һәм хәбәрнең урыннары. Исемнәр һәм хикәя фигыльләр белән бирелгән гади хәбәрләр. Җөмләдә сүзләр бәйләнеше. Җөмләдәге сүзгә, шул сүздән башка сүзләргә сораулар кую һәм сүзтезмәдә ияртүче, ияртүче сүзләрне билгеләү. Җыйнак һәм җәенке җөмләләр. Җыйнак җөмләне, тиешле сүзләр өстәп, җәенкеләндерә белү, җәенке җөмлә эченнән баш кисәкләрне генә аерып чыгару. Тиңдәш ияле һәм тиңдәш хәбәрле җөмләләр. Тиңдәш кисәкләр арасында *һәм, я, да/дә, та/тә, ә, ләкин* теркәгечләре.<br><br>* Текстның темасы һәм төп фикере. Исемсез текстларның темасын билгеләү һәм исем кую. Төп фикерне темадан аера белү һәм аларны төгәл билгеләү. Тексттагы җөмләләрнең зат алмашлыклары, *һәм, ә, ләкин* теркәгечләре һәм синонимнар ярдәмендәберләшүе. Текст берәмлекләрен сүз тәртибе |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 14.Ел буена үткәннәрне кабатлау | | ярдәмендә оештыру. Текст кисәкләрен берләштерүдә кирәкле сүзләр: *алдан, аннан, аннан соң, аннары, (иң) ахырда, әүвәл, башлап, башта, баштан, соңында, соңыннан, элек һ.б.*<br>Текстларның типлары: хикәяләү, тасвирлама, фикер йөртү. Аларның төп үзенчәлекләре. Дәрес темасына бәйле рәвештә аларны телдән төзү, кечкенә күләмлеләрен язып кую.<br>Әзер яки күмәк төзелгән план буенча хикәяләү тибындагы текстны изложение итеп язу. Сюжетлы рәсемнәр һәм картиналар буенча, укучыларның тормыш тәҗрибәсе, күзәтүләренә, укыганнарына бәйле темаларга, алдан әзерлек күреп, сочинениеләр язу. Иҗади эшләргә тасвирлама, фикер йөртү тибындагы текст элементларын кертү. Телдән эш характерындагы текстлар (автобиография, адрес, гариза, аңлатма язу) төзү.<br>Сөйләм этикасы. Телдән һәм язып чакыру, тәбрикләү, мөрәҗәгать итү, гафу үтенү. |
| | | | |

**Календарь – тематик план**

| № | Дәреснең темасы | Дата | | Укытучы һәм укучы эшчәнлеге төре |
|---|---|---|---|---|
| | | план | факт | |
| 1 | Сүз. Сүзнең төп (лексик) мәгънәсе | 1.09 | | Лексик төшенчәсен аңлату,аңлатмалы сүзлекләр белән эш,хезмәтләрне бәяләү, төзәтү; татар теленең сүз байлыгы, сүзнең лексик мәгънәсе; лексик мәгънәгә туры килгән сүзләр табу. Орфографик, аңлатмалы сүзлекләр белән эшләү. Сүзлекләрнең төрләре белән танышу. Сүзләрнең мәгънәләре, туры һәм күчерелмә мәгънә; сөйләмдә куллану |
| 2 | Аңлатмалы сүзлекләр белән эш. Бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләр | 2.09 | | |
| 3 | Охшаш мәгънәле сүзләр-синонимнар. Сөйләмдәге роле. | 4.09 | | Иҗади эш,сүзләрнең мәгънәләре, синоним төшенчәсе; сөйләмдә тиешлесен куллану. Уртак мәгънәле, бер-берсеннән мәгънә төсмерләре һәм язылышлары белән генә аерылып торучы сүзләрнең синоним дип аталуын өйрәнү. Синоним сүзләрне дөрес билгеләү. Аларны сүзтезмә һәм җөмлә төзегәндә дөрес куллану. |
| 4 | Капма-каршы мәгънәле сүзләр- антонимнар | 8.09 | | Капма-каршы мәгънәле сүзләр- антонимнарны табу,белем һәм күнекмәләрне практикада куллану. |
| 5 | Әйтелеше бертөрле, мәгънәләре башка сүзләр-омонимнар . | 9.09 | | Әйтелеше һәм язылышы яыннан бертөрле, ләкин төрле мәгънәгә ия булган сүзләр омонимнар дип атала. Омоним сүзләр арасында мәгънә уртаклыгы булмый. Омонимнар турында төшенчә бирү, аларны аера белү күнекмәсе формалаштыру..Сүзләрнең мәгънәләре, сорау кую; омоним төшенчәсе |
| 6 | Әйтелеше бертөрле, мәгънәләре башка сүзләр-омонимнар . Иҗади биремле күнегүләр. Тест. | 11.09 | | сүзләрнең мәгънәләре, сорау кую; омоним төшенчәсе Әйтелеше һәм язылышы яыннан бертөрле, ләкин төрле мәгънәгә ия булган сүзләр омонимнар дип атала. Омоним сүзләр арасында мәгънә уртаклыгы булмый. Омонимнар турында төшенчә бирү, аларны аера белү күнекмәсе формалаштыру. |
| 7 | Авазлар һәм хәрефләр. | 15.09 | | Парларда эш. Авазларны һәм хәрефләрне аера белү. Матур язу өстендә эш. Калын һәм нечкә сузыкларны аерып, татар телендәге сүзләрнең сингармонизм законына буйсынуын яки |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | буйсынмавын аңлау. |
| 8 | Кереш диктант. | 16.09 | | Орфограммаларны кулланып диктант язу. Алган белем күнекмәләрне тикшерү һәм бәяләү. |
| 9 | Хаталар өстендә эш. Сүз төзелеше. Сүз ясалышы.Аваз һәм хәреф турында 1-2 нче сыйныфларда үткәннәрне кабатлау | 18.09 | | Орфография сүзенең мәгънәсен ачыклау. |
| 10 | Сузык авазлар. Иҗек. | 22.09 | | Сүздә ничә сузык аваз, шулкадәр иҗек булу һәм иҗек чиген сүзне әйтеп, укып карап белеп булуы белән таныштыру. Матур язу өстендә эшләү. Сөйләм телен һәм фикер йөртү сәләтләрен үстерү ,иҗек төзелеше, саны, аваз һәм иҗек анализы |
| 11 | Тартык авазлар. | 23.09 | | Тартык авазлар, яңгырау һәм саңгырау тартыкларны аеру, парлау |
| 12 | Иҗек. Сүзләрне юлдан юлга күчерү. Аваз-хәреф анализы. | 25.09 | | Иҗек төзелеше, саны, аваз һәм иҗек анализы Сүзләрне юлдан юлга күчерү. Сүздәге иҗекләрнең саны сузык авазларга бәйле. Гадәттә һәр иҗектә бер сузык аваз була. |
| 13 | Ъ,ь хәрефләре. | 29.09 | | Ь һәм ъ хәрефләре булган сүзләрне дөрес уку һәм язу.Нечкәлек һәм аеру, калынлык һәм аеру билгеләре; дөрес язылышына күнегүләр |
| 14 | Аваз–хәреф анализы. Я, ю, е хәрефләре. | 30.09 | | Е хәрефенең (йы), (йе) аваз кушылмаларына, Я хәрефенең (йа), (йә) аваз кушылмаларына, Ю хәрефенең (йу), (йү) аваз кушылмаларына ия булып йөрүе буенча белемнәрен камилләштерүПарларда эш, әйтелеш һәм язылыш, аваз кушылмалары |
| 15 | “Авазлар һәм хәрефләр” темасы буенча контроль күчереп язу. | 2.10 | | 55-60 сүзле текстны, хәрефен бозмыйча, төшереп калдырмыйча, хәреф өстәмичә, урыннарын алыштырмыйча, каллиграфик дөрес язу.,текстны грамоталы һәм каллиграфик дөрес итеп күчереп язу |
| 16 | Хаталар өстендә эш. Алфавит. Иҗади биремле күнегүләр. Тест | 6.10 | | алфавит тәртибе; аваз һәм хәреф саны, әйтелеше, исеме, язылышы; сүзлекләр белән эшләү |
| 17 | Сүз төзелеше. Тамыр һәм кушымча. Тамырдаш сүзләр. | 7.10 | | Сүзнең мәгънәле кисәкләре: тамыр һәм кушымча, ясагыч кушымча табу.<br>Төрләндергеч кушымча. сүз төзелеше, тамыр һәм кушымчаны билгеләү; тамырдаш сүзләр табу. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 18 | Сүз ясагыч кушымалар | 9.10 | | Сүз ясалышы, ясагыч кушымчалар, алар ярдәмендә сүзләр ясалуын карау, ясау; ясалма сүзләр .Кушымчалар ике төрле була” сүз ясагыч кушымчалар һәм мөнәсәбәт белдерүче кушымчалар. Сүз ясагыч кушымчаларны аера белү. |
| 19 | Бәйләгеч кушымчалар.<br>Бәйләнешле сөйләм “Көзге уңыш” хикәя төзеп язу. | 13.10 | | Төрләндергеч кушымчалар, алар ярдәмендә сүзләрнең үзгәрүен күзәтү; үзгәртү,парларда эш .Кушымчалар ике төрле була” сүз ясагыч кушымчалар һәм мөнәсәбәт белдерүче кушымчаларю Җөмлә, аның чикләре, төрләре; тыныш билге-ләре,; баш кисәкләр; картина буенча укучы-ларның тормыш тәҗрибәсе, күзәтүләренә бәйле хикәя төзү; эзлеклелек, сүз тәртибе, дөрес яз |
| 20 | Хаталар өстендә эш. Иҗади биремле күнегүләр.<br>Тест. | 14.10 | | Укучыларның белем күнекмәләрен ныгыту<br><br>Алган белем күнекмәләрне тикшерү һәм бәяләү. |
| 21 | Искәртмәле диктант. | 16.10 | | орфограммаларны кулланып, җөмлә ахырында тиешле тыныш билгесе куеп, диктант язу; аваз-хәреф анализы; иҗеккә бүлү буенча биремнәр үтәү . |
| 22 | Хаталар өстендә эш.“Кушымчалар” темасына күнегүләр эшләү. | 20.10 | | Хаталарны анализлау.Хаталар өстендә эш.Сүзнең мәгънәле кисәкләре: тамыр һәм кушымча, ясагыч кушымча табу.<br>Төрләндергеч кушымча. сүз төзелеше, тамыр һәм кушымчаны билгеләү; тамырдаш сүзләр табу.<br>Бәйләнешле сөйләм хикәя төзеп язарга өйрәтү.<br>Алган белем күнекмәләрне тикшерү һәм бәяләү.<br>Сүзләрнең төркемнәргә бүленеше: исем, фигыль, сыйфат, алмашлык.,хезмәтләрне анализлау; сүз ясалу төрләре, сүзләр ясау |
| 23 | Бәйләнешле сөйләм хикәя төзеп язу “Кыш килә” | 21.10 | | |
| 24 | Сүз төркемнәре. Сүзләрнең төркемнәргә бүленеше. | 23.10 | | |
| 25 | Исем. Мәгънәсе, сораулары, җөмләдәге роле.<br>Искәртмәле диктант . | 27.10 | | Исем темасы буенча белемнәрне ныгыту.Парларда эш, исем төшенчәсе, мәгънәсе, сораулары, төркеме, җөмләдәге роле |
| 26 | Ялгызлык исемнәр. | 10.11 | | Ялгызлык исемнәргә кеше исемнәре, фамилияләр, елга, авыл, шәһәр исемнәре, хайван кушаматлары керә. Алар баш хәрефтән языла. Иҗади эш, ялгызлык төшенчәсе, төркемнәре, язылышы |
| 27 | Уртаклык исемнәр. Сүзлек диктанты. | 11.11 | | Ялгызлык исемнәрдән кала барлык исемнәр дә уртаклык исемнәр була. Җөмлә башында гына баш хәрефтән языла, калган очракларда юл хәрефтән язылалар.,уртаклык төшенчәсе, |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | язылышы, алган белемнәрне практикада куллану |
| 28 | Берлек һәм күплек сандагы исемнәр. | 13.11 | | Исемнәрнең берлек һәм күплек санда килүе белән танышу. берлек һәм күплек сан формалары, берлектән-күплек, күплектән-берлек ясау; борын авазларын тану, күплек форма ясау, язылыш |
| 29 | Исемнәрнең килеш белән төрләнеше. | 17.11 | | Исемнәр килеш белән төрләнә. Килеш кушымчалары сүзләрне аера белү өчен кулланыла.килеш төшенчәсе, җөмләдә бәйләүче роле, атамалары, сораулары; калын һәм нечкә төрләнеш |
| 30 | Баш килеш. | 18.11 | | Баш килеш белән таныштыру. Җөмләдә баш килештә килгән исемнәрне табу.исемнәрне табу, сорау кую, баш килеш төшенчәсе, сораулары |
| 31 | Иялек килеш. | 20.11 | | Иялек килеш белән таныштыру. Җөмләдә иялек килешендә килгән исемнәрне табу.Парларда эш, исемнәргә сорау кую; иялек килеш төшенчәсе, сораулары, кушымчары; калын һәм нечкә төрләнеш |
| 32 | Юнәлеш килеш. | 24.11 | | Юнәлеш килеш белән таныштыру. Җөмләдә юнәлеш килешендә килгән исемнәрне табу.исемнәргә сорау кую;<br>Төшем килеш белән таныштыру. Җөмләдә төшем килешендә килгән исемнәрне табу.төшем килешләре төшенчәсе, сораулары, кушымчалары; калын һәм нечкә төрләнеш; саңгырау һәм яңгырау тартыкларга, сузык авазга беткән исемгә кушымча ялгау |
| 33 | Төшем килеш. | 25.11 | | |
| 34 | Чыгыш килеш. | 27.11 | | Чыгыш килеш белән таныштыру. Җөмләдә чыгыш килешендә килгән исемнәрне табу.исемнәргә сорау кую; чыгыш килеш төшенчәсе, сораулары, кушымчалары; калын һәм нечкә төрләнеш; борын аваз-ларына беткән исемнәргә чыгыш килеш кушымчасы ялгау |
| 35 | Урын-вакыт килеше. | 1.12 | | Урын-вакыт килеш белән таныштыру. Җөмләдә урын-вакыт килешендә килгән исемнәрне табу.исемнәргә сорау кую; урын-вакыт килеше төшенчәсе, сораулары, кушымчалары; калын һәм нечкә төрләнеш |
| 36 | Изложение язу “Песи баласы” | 2.12 | | Өйрәнгән кагыйдәләргә нигезләнеп тыңлаганның эчтәлеген изложение итеп язу |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 37 | Хаталар өстендә эш. Ныгыту күнегүләре. Исем сүз төркеме. | 4.12 | | орфограммаларны кабатлау; яңгырау һәм саңгырауга, сузык авазга, борын авазына беткән исемнәр,аларны төрләндерү, анализлау |
| 38 | Күчереп язу. | 8.12 | | текстны грамоталы һәм каллиграфик дөрес итеп күчереп язу |
| 39 | Хаталар өстендә эш.  Фигыль. | 9.12 | | Фигыль турында белемнәрне үстерү, ныгыту, камилләштерү.фигыль төшенчәсе, мәгънәсе, сораулары, эшне, хәрәкәтне, хәлне белдерүче фигыльләр; җөмләдәге роле |
| 40 | Фигыльләрнең барлык һәм юклык төрләре. | 11.12 | | Фигыль барлыкта һәм юклыкта төрләнә.;барлык һәм юклык төшенчәсе, сорау кую, фи-гыльнең барлык, юклык төрен билгеләү; басым; язылыш |
| 41 | Фигыльләрнең зат-сан белән төрләнеше | 15.12 | | Фигыльләр зат һәм сан белән төрләнә. Фигыльләр 1, 2, 3 затта һәм берлек, һәм күплек санда төрләнә.<br>зат һәм сан төшенчәсе, фигыльләрнең төрләнеше; ия белән фигыльнең ярашуы |
| 42 | Фигыль заманнары. | 16.12 | | Фигыль заманнары белән танышу |
| 43 | Хикәя фигыль. Хикәя фигыльнең заман белән төрләнүе. | 18.12 | | Хикәя фигыль хәзерге заманда, үткән заман, киләчәк заманда төрләнә. |
| 44 | I яртыеллык өчен административ  контроль диктант | 22.12 | | орфограммаларны кулланып, диктант язу, фигыль темасы буенча биремнәрне үтәү |
| 45 | Хаталар өстендә эш. Хәзерге заман хикәя фигыль. | 23.12 | | Хәзерге заман хикәя фигыль эшнең хәзер үтәлүен белдерә һәм нишли? Соравына җавап булып килә. |
| 46 | Тартык авазларга беткән фигыльләр хәзерге заманда. | 25.12 | | тартык авазга беткән  фи-гыльләргә ялганучы ку-шымчалар, калын һәм нечкә төрләнеш, зат-сан белән төрләндерү |
| 47 | Сузык авазларга беткән фигыльләр хәзерге заманда. | 29.12 | | сузык авазга беткән  фи-гыльләргә ялганучы ку-шымчалар; калын һәм нечкә төрләнеш; зат-сан белән төрләндерү |
| 48 | [п], [къ], [к] авазларына беткән фигыльләр хәзерге заманда | 12.01 | | тамырда авазлар чират-лашуы; дөрес язу күнекмәләре |
| 49 | Бәйләнешле сөйләм  “Кышкы уеннар”. Рәсем буенча хикәя төзү. | 13.01 | | картина буенча укучы-ларның тормыш тәҗри-бәсе, күзәтүләренә бәйле хикәя төзү;  өйрәнелгән сүзләр куллану, |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | эзлеклелек, дөрес язылыш |
| 50 | Үткән заман хикәя фигыльнең төрләре, барлык һәм юклык формалары. | 15.01 | | Үткән заман хикәя фигыль эшнең үткәнен белдерә. Һәм нишләгән? Соравына җавап булып килә.<br>-ган,-гән,-кан,-кән ,билгеле һәм билгесез үткән заман, аның кушымчалары, язылышы |
| 51 | Үткән заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. | 19.01 | | үткән заман хикәя фигыльне дөрес, урынлы файдалану, төрләндерү |
| 52 | Киләчәк заман хикәя фигыль. | 20.01 | | киләчәк заман хикәя фигыльнең белдерелеше, сораулары, кушымчалары; сөйләмдә аларны аера белү |
| 53 | Киләчәк заман хикәя фигыльнең беренче төре | 22.01 | | киләчәк заман хикәя фи-гыльнең икенче төре; калын һәм нечкә төрләнеш; тамырда авазлар чиратлашуы |
| 54 | [П],[къ], [к]тартыкларына беткән киләчәк заман хикәя фигыльләре | 26.01 | | Зат-сан белән төрләндерү |
| 55 | Киләчәк заман хикәя фигыльнең икенче төре | 27.01 | | Парларда эш, киләчәк заман хикәя фи-гыльнең икенче төре; калын һәм нечкә төрләнеш; тамырда авазлар чиратлашуы |
| 56 | Боерык фигыль | 29.01 | | Боерык фигыльне практикада куллану |
| 57 | Фигыль темасы буенча грамматик биремле диктант | 2.02 | | орфограммаларны кулланып диктант язу; фигыльнең заманнарын билгеләү |
| 58 | Хаталар өстендә эш.Фигыльләрнең күп мәгънәлелеге | 3.02 | | синоним, антоним фи-гыльләр һәм сыйфатлар, сөйләмдә куллану |
| 59 | Туры һәм күчерелмә мәгънәле сүзләр. | 5.02 | | җөмләдәге роле, аларны билгели алу |
| 60 | Туры һәм күчерелмә мәгънәле сүзләр. | 9.02 | | җөмләдәге роле, аларны билгели алу |
| 61 | Сыйфатларның сөйләмдәге әһәмияте. | 10.02 | | Сыйфат турында белемнәрне тирәнәйтү, ныгыту, камилләштерү.<br>-хезмәтләрне коррекцияләү; сыйфатның сөйләмдәге әһәмиятен билгеләү, кулланылышын карау<br>Антоним сыйфатларны куллану. |
| 62 | Сүзтезмәләрдәге сыйфатлар. Антоним сыйфатлар | 12.02 | | |
| 63 | Сыйфат дәрәҗәләре. Гади дәрәҗә. | 16.02 | | Сыйфат дәрәҗәләре төп (гади) , чагыштыру, артыклыккимлек, сыйфат дәрәҗәләренең ясалышы, аларның дөрес язылышы |
| 64 | Чагыштыру дәрәҗәсендәге сыйфатлар | 17.02 | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 65 | Артыклык дәрәҗәсендәге сыйфатлар | 19.02 | | |
| 66 | Кимлек дәрәҗәсендәге сыйфатлар | 23.02 | | |
| 67 | Сыйфат темасына иҗади биремле күнегүләр. Тест биремнәре | 24.02 | | |
| 68 | Сыйфат темасы буенча контроль диктант. | 26.02 | | Орфограммаларны кулланып диктант язу, сүз төркемнәрен билгеләү |
| 69 | Хаталар өстендә эш. Алмашлык. | 1.03 | | Алмашлыклар белән таныштыру. |
| 70 | Зат алмашлыклары | 2.03 | | Алмашлыклар 1, 2, 3 зата килә һәм берлек, күплек санда төрләнәләр. |
| 71 | Берлек сандагы зат алмаш-лыкларының килеш белән төрләнеше.Сүзлек диктанты. | 4.03 | | Берлек сандагы зат ал-машлыкларын килеш белән төрләндерү; дөрес әйтелеш һәм язылыш Зат алмашлыклары баш килешендә, иялек, юнәлеш, төшем, чыгыш, урын-вакыт килешендә төрләнәләр. |
| 72 | Күплек сандагы зат алмашлык-ларының килеш белән төрләнеше. | 8.03 | | күплек сандагы зат ал-машлыкларын килеш белән төрләндеү; дөрес язылыш өстендә эшләү |
| 73 | Бәйләнешле сөйләм. “Без спорт яратабыз.” | 9.03 | | Бәйләнешле сөйләм хикәя төзеп язарга өйрәтү. Зат алмашлыкларын табу, сөйләмдә куллану, тикшерү |
| 74 | Кисәкчәләр. Да,дә, та, тә | 11.03 | | Ярдәмче сүзләрне сөйләмдә куллану, тикшерү, кисәкчәләрне билгеләү |
| 75 | Генә, кына ,бит кисәкчәләре | 15.03 | | |
| 76 | Ич, ук-үк, һич кисәкчәләре | 16.03 | | |
| 77 | Бәйләнешле сөйләм. “Өмәдә” хикәя язу | 18.03 | | төрле сүзләр янында килүе; текстта кисәкчәләрне таба белү, куллану. Бәйләнешле сөйләм хикәя төзеп язарга өйрәтү. |
| 78 | Кисәкчәнең сөйләмдәге роле, язылышы. | 22.03 | | да, дә, та, тә, гына, генә, кына, кенә, ич, бит,ук,үк кисәкчәләре, аларның мәгънәләре кисәкчәләрнең кулланы-лышы, язылышы, аерым сүз булуы; калын һәм нечкә әйтелешле кисәкчәләрне билгеләү |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 79 | Бәйлекләр. | 1.04 | | Бәйлекләр белән таныштыру. Төрле килешләрдә исемнәрнең һәм зат алмашлыкларының бәйлекләр белән килүен күзәтү.хезмәтләрне анализлау, ярдәмче сүз төркеме буларак бәйлек; җөмләдәге роле |
| 80 | Бәйлекләрнең исемнәр һәм алмашлыклар белән килүе | 5.04 | | Бәйлекнең җөмләдәге роле Бәйлекләр белән таныштыру. Төрле килешләрдә исемнәрнең һәм зат алмашлыкларының бәйлекләр белән килүен күзәтү. |
| 81 | Нәрсә ул җөмлә. Сүзлек диктанты. | 6.04 | | Парларда эш, җөмлә төшенчәсе; укылыш, тавыш куелышын тыныш билгесенә карап билгеләү; тасвирлау, фикер йөртү элементлары кертү |
| 82 | Хикәя җөмлә. | 8.04 | | Хикәя җөмлә тыныч тойгы белән укыла.әйтелеш максаты буенча төрләрен билгеләү. Сөйләм төзү |
| 83 | Бәйләнешле сөйләм “Яз һәм кошлар”. Сорау җөмлә. | 12.04 | | Бәйләнешле сөйләм үстерү күнегүәре. |
| 84 | Өндәү (боеру) җөмлә. Тойгылы җөмлә | 13.04 | | Өндәү җөмләү көчле тойгы белән укыла, әмер бирү, сөенүне белдерергә мөмкин.Парларда эш, әйтелеш максаты буенча төрләре- өндәү җөмлә, белдерелеше, тыныш билгесе, җөмләләр төзү<br>Көчле төйгы белән җөмлә төзү |
| 85 | “Җөмлә” темасы буенча күчереп язу<br>Мәңге сүнмәс умырзаялар | 15.04 | | текстны грамоталы һәм каллиграфик дөрес итеп күчереп язу |
| 86 | Хаталар өстендә эш. Җөмлә кисәкләре. Җөмләдә сүзләр бәйләнеше | 19.04 | | Җөмләнең баш кисәкләре: ия белән хәбәр белән танышу. Дөрес матур язу өстендә эшләү. Сөйләм төзү һәм фикер йөртү ,җөмләнең баш һәм ияр-чен кисәкләре: ия һәм хәбәр, аларның белдерелеше, сораулары, язуда билгеләү |
| 87 | Җыйнак һәм җәенке җөмләләр. | 20.04 | | Хезмәтләргә бергәләп бәя бирү, хаталарны төзәтү; җыйнак һәм җәенке җөмлә төшенчәсен аңлату; чагыштыру, аеру, куллану |
| 88 | Сүзтезмә. Сүзтезмәдә сүзләр бәйләнеше. | 22.04 | | Җөмләдәге сүзгә, шул сүздән башка сүзләргә сораулар кую һәм сүзтезмәдә ияртүче, иярүче сүзләрне билгеләү<br>Сүзтезмә төшенчәсе, аларны аера белү, сораулар кую |
| 89 | Сүзтезмәдә сүзләр бәйләнеше. | 26.04 | | |
| 90 | Сүзтезмә темасы буенча Аңлатмалы диктант. | 27.04 | | орфограммаларны кул-ланып диктант язу; җөмлә кисәкләрен билгеләү |
| 91 | Текст. Тема. | 29.04 | | Текст, аның темасы, төп фикере, бүлек башы, текстның кисәкләре, алар арасындагы һәм җөмләләр арасындагы бәйләнеш, укучыларның текст планын кабатлау |
| 92 | План.Текстның өлешләре. | 3.05 | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | Әйтмә һәм язма сөйләм; текст, текстның өлешләре, мәгънәле кисәкләре арасында бәйләнеш; исем кую, хикәяләү, тасвирлау, фикер йөртү төрләрен аеру текстның төп уе- тема; теманы билгеләү, мисаллар китерү мәгънәле кисәкләрне билгеләп гади план төзү,план буенча эчтәлек сөйләү |
| 93 | Сөйләм этикасы. Эндәш сүзләр | 4.05 | | Укучыларны матур һәм дөрес сөйләшә белергә өйрәтү, тылсымлы сүзләрне урынлы куллана белергә өйрәнү .Сөйләм этикасы белән танышу,план төзү; язма сөйләм нормаларын, язылыш кагыйдәләрен искә төшерү |
| 94 | Тасвирлау һәм хикәяләү текстлары. Автобиография. | 6.05 | | Тасвирлаухезмәтләрне бергәләп бәяләү, хаталарны классификацияләү, автобиография язу үзенчәлеге Тасвирлау һәм хикәяләү текстлары төзү күнекмәсен булдыру |
| 95 | Сурәтләү һәм хикәяләү текстлары | 10.05 | | Һәр абзацка исем кую, план төзү,эчтәлек сөйләү,орфограммаларны табу,эчтәлеген язу |
| 96 | Изложение яздыру.№3 | 11.05 | | Алган белем күнекмәләрне тикшерү һәм бәяләүТекст өстендә эш, план төзү,спорт ярышлары темасына изложение язу |
| 97 | Хаталар өстендә эш Иҗади биремле күнегүләр. Тест. | 13.05 | | Укучыларның алган белемнәрен ныгыту һәм камилләштерү. |
| 98 | Уку елында өйрәнгән орфограммаларны ныгыту. | 17.05 | | Алган белем күнекмәләрне тикшерү һәм бәяләү |
| 99 | Уку елында өйрәнгән сүз төзелешен ныгыту | 18.05 | | Укучыларда язма һәм әйтмә сөйләм күнекмәләре булдыру |
| 100 | Административ (йомгаклау) контроль диктанты | 20.05 | | Орфограммаларны кулланып диктант язу; җөмлә кисәкләрен билгеләү |
| 101 | Хаталар өстендә эш. | 24.05 | | |
| 102 | Уку елын йомгаклау. | 25.05 | | |

**Литература:**

1.Татарский язык. 1, 2 часть. Учебник Ч. М. Харисов,Г. Р. Шакирова издательство “ Магариф - время” 2013 год

2.примерные программы по татарскому языку и литературе для средних общеобразовательных школ на татарском языке. 1-11 классы казанские татары.книга. издательство 2011 год

Дополнительная литература.

1. Абдрахимова Я. Х. "диктанты по татарскому языку" 1-4 класс. Казань:” Образование " - 2009.
2. Вагизов с. г. “Интересная грамматика” Казань: “образование” - 2002.
3. Абдрахимова Я. Х. “Упражнения для самостоятельной работы ” Казань: “образование” - 2007.

Интернет-ресурсы

Татарская электронная библиотека http://kitap.net.ru/;

Образовательный интернет татарском языке http://belem.r

**Кулланылган әдәбият:**

1.Татар теле 1 кисәк, 2 кисәк дәреслек Ч.М.Харисов,Г.Р.Шакирова “ Мәгариф- вакыт” нәшрияты 2013 ел

2. Татар телендә урта гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар. 1-11 нче сыйныфлар Казан Татар. китап. нәшрияты 2011 ел

**Өстәмә әдәбият:**

1.Абдрәхимова Я. Х. “Татар теленнән диктантлар” 1-4 класс. Казан: “Мәгариф” - 2009.
2.Вагыйзов С. Г. “Кызыклы грамматика” Казан: “Мәгариф” - 2002.
3. Абдрәхимова Я. Х. “Татар теленнән мөстәкыйль эшләү өчен күнегүләр” Казан: “Мәгариф” - 2007.

**Интернет – ресурслар**

Татар электрон библиотекасы http://kitap.net.ru/;

Татар телендә интернет белем үзәге http://belem.r

Кушымта

**3 нче сыйныфта язма эшләрнең күләме һәм бәяләү нормалары**

Контроль диктант – 4

Изложение - 4

Сочинение – 3

<u>Сүзлек диктантын бәяләү</u>

1. Пөхтә язылган, хатасы булмаган эшкә “5” ле куела.
2. Бер орфографик хаталы эшкә “4” ле куела.
3. 3 орфографик хаталы эшкә “3” ле куела.
4. 5 орфографик хаталы эшкә “2” ле куела.

<u>Контроль диктантны бәяләү:</u>

1. Эш пөхтә башкарылса, хатасы булмаган эшкә “5” ле куела. (Бер – орфографик, ике пунктуацион хата булырга мөмкин.)
2. Ике орфографик, ике пунктуацион яки бер орфографик, дүрт пунктуацион хаталы эшкә “4” куела.
3. Дүрт орфографик, дүрт пунктуацион яки өч орфографик, алты пунктуацион хаталы эшкә “3” куела.
4. Алты орфографик, биш пунктуацион яки биш орфографик, сигез пунктуацион хаталы эшкә “2” куела.

<u>Изложениене бәяләү</u>

1. Тема тулысынча ачылган, фактик һәм техник хаталары булмаган, стиль бердәмлеге сакланган эшкә «5» ле куела. (Бер орфографик, ике пунктуацион яки ике грамматик хатасы булырга мөмкин.

2. Текстның эчтәлеге темага нигездә туры килсә, фикерне белдерүдә зур булмаган ялгышлыклар җибәрелсә, бер-ике фактик, бер-ике техник хатасы булса, ике орфографик, ике-өч пунктуацион, бер грамматик хатасы булган эшкә«4» ле куела.

3. Язмада эчтәлек эзлекле бирелмәсә, стиль бердәмлеге сакланмаса, өч фактик, ике-өч техник хатасы булса, өч орфографик, дүрт пунктуацион, ике грамматик хатасы булган эшкә «3» ле куела.

4. Эзлеклелек, стиль бердәмлеге сакланмаса, язма эш планга туры килмәсә, фактик һәм техник хаталары күп булса, орфографик хаталарның саны дүрттән, пунктуацион хаталарның саны биштән, грамматик хаталар саны өчтән артса,«2» ле куела.

<u>Сочинениене бәяләү</u>

1. Язманың эчтәлеге темага тулысынча туры килсә, фактик ялгышлары булмаса, бай телдә, образлы итеп язылса, стиль бердәмлеге сакланса, «5» ле куела. (Бер орфографик яисә ике пунктуацион (грамматик) хата булырга мөмкин.)

2. Язманың эчтәлеге нигездә темага туры килсә, хикәяләүдә зур булмаган ялгышлыклар күзәтелсә, бер-ике фактик хата җибәрелсә, теле бай, стиль ягы камил булып, ике орфографик, өч пунктуацион (грамматик) яисә бер-ике сөйләм ялгышы булса, «4» ле куела.

3. Эчтәлекне бирүдә җитди ялгышлар, аерым фактик төгәлсезлекләр булса, хикәяләүдә эзлеклелек югалса, сүзлек байлыгы ярлы булса, стиль бердәмлеге дөрес сакланмаган җөмләләр очраса, 6 орфографик, 6 пунктуацион (грамматик) яисә өч-дүрт сөйләм хатасы булса, «3» ле куела.

4. Язма темага туры килмичә, фактик төгәлсезлекләр күп булып, план нигезендә язылмаса, сүзлек байлыгы бик ярлы булса, текст кыска һәм бер типтагы җөмләләрдән торып, сүзләр дөрес кулланылмаса, стиль бердәмлеге сакланмаса, биш орфографик, сигез пунктуацион (грамматик) яисә дүрт—алты сөйләм хатасы булса, «2» ле куела.

“5”- укучы программа материалын аңлап һәм логик эзлеклелекә үзенеңкүзәтүләрен һәм гамәли эш нәтиҗәләрен файдаланып бәя итсә, табигатьтәге күренешләр, бәйләнешләр ураштырса, дәреслектәге тексттан дөрес җавапны таба белсә, куелган сорауларга тулы җаваплар бисә;
“4”- “5” ле таләбенә туры килсә, ләкин материалны бәян иткәндә, аерым теминнарны кулланганда кайбер төгәлсезлекләр җибәрсә;
“3”- уку материалының төп эчтәлеген үзләштерсә, ләкин фактик хаталар җибәрсә, табигатьне күзәтү,гамәли эш нәтиҗәләрен файдалана белмәсә, табигатьтәгекүренешләр, объектлар, табигать һәм кеше арасында бәйләнеш булдырырга кыенсынса, ләкин күрсәтелгән җитешсезлекләрне, дәреслектән файдаланып укытучы ярдәмендә төзәтсә;
“2”- программа материалының шактый өлешен белмәсә, гамәли эшләрне укытучы ярдәмендә дә үти алмаса;
“1”- программа материалын бөтенләй белмәсә, куелган сорауларның берсенә дә җавап бирә алмаса яки дөрес җавап бирмәсә.

| | Контроль диктант өчен нормалар | | Сүзлек диктанты өчен |
|---|---|---|---|
| Сыйныф | I – яртыеллык | II - яртыеллык | |
| I | - | 15 – 17 сүз | - |
| II | 25 – 30 сүз | 35 – 40 сүз | 8 – 10 |
| III | 45 – 50 сүз | 55 – 60 сүз | 10 – 12 |
| IV | 65 – 70 сүз | 75 – 80 сүз | 12 – 15 |

Изложение өчен текстларның күләме һәр сыйныфта 15 – 20 сүзгә артыграк булл

3 сыйныфта татар теленнән диктант үрнәкләре.

## **Безнең бакча.**

Безнең авыл тау буенда утыра. Ерак түгел бер инеш бар. Балык күп анда. Эссе көннәрдә без шул инештә су керәбез.
Мәктәп янында бакчабыз бар. Анда алмагачлар, чияләр үсә. Аларны утырткан малайлар һәм кызлар инде укып чыкканнар.
Әнә яшелчә-җимеш бакчасы. Аны без утырттык, үзебез үстерәбез. Быел кәбестә, кыяр, суган, помидор бик яхшы үсә. (53 сүз.)

## **Изложение**

## **Песи.**

Минем кап-кара песием бар.Үзе бик матур. Йолдызкай исемле. Иртән минем белән бергә йокыдан тора. Бергәләп зарядка ясыйбыз. Аннан соң икебез дә юынабыз. Песи юынырга су янына барып тормый. Алгы тәпиләре белән битен һәм колак артларын юа. Көндез ул ялгызы була. Шулай да үзен тәртипле тота. Безнең мәктәптән кайтуны зарыгып көтә. Рөхсәтсез бер әйбергә дә тими. Ап-ак тәпиләрен бик чиста итеп саклый. Чиста тәлинкәдән сөт эчәргә бик ярата. Безнең тәртипле песигә күршеләр дә соклана.

**Текстка карата сораулар**

1.Минем нинди песием бар?
2.Аның исеме ничек?
3.Иртән песи минем белән бергә нишли?
4.Көндез песи үзен ничек тота?
5.Йолдызкай нишләргә бик ярата?
6.Күршеләр песигә ни өчен соклана?

**Текстны өлешләргә бүл**

Минем кап-кара песием бар.Үзе бик матур. Йолдызкай исемле.

Иртән минем белән бергә йокыдан тора. Бергәләп зарядка ясыйбыз. Аннан соң икебез дә юынабыз. Песи юынырга су янына барып тормый. Алгы тәпиләре белән битен һәм колак артларын юа.

Көндез ул ялгызы була. Шулай да үзен тәртипле тота. Безнең мәктәптән кайтуны зарыгып көтә. Рөхсәтсез бер әйбергә дә тими. Ап-ак тәпиләрен бик чиста итеп саклый. Чиста тәлинкәдән сөт эчәргә бик ярата.

Безнең тәртипле песигә күршеләр дә соклана.

**План төзү**

1.Йолдызкай- матур песи.
2.Песинең көндәлек режимы бар.
3.Безнең песи чисталык ярата.
4.Тәртипле Йолдызкайга күршеләр дә соклана.

**Ябалак.**

Без урманда ябалак таптык. Ябалакның канаты имгәнгән. Ул оча алмый. Без ябалакны өйгә алып кайттык. Ябалактан тавыклар курыктылар.Ишек алдының бер почмагына ябалакка оя ясадык. Аңа ашарга, эчәргә бирдек. Ул бик тиз терелде. Ябалакта үзгәреш күренә башлады. Ябалакның иреккә чыгасы килде.

Караңгы төште. Без ябалакны иреккә очырдык. (47 сүз.)

Бирем.

1.Ябалакның,канаты,имгәнгән сүзләрен иҗекләргә бүлеп язарга.

2.Ике иҗекле сүзләрне иҗекләргә бүлеп язарга.

Контроль күчереп язу.

**Татарстан.**

Без Татарстанда яшибез. Татарстан бик зур һәм бай. Анда Казан, Чистай, Алабуга, Бөгелмә, Әлмәт, Җәлил, Чаллы, Түбән Кама һәм башка шәһәрләр бар.

Татарстанда зур елгалар ага. Татарстанны Идел, Кама, Агыйдел, Зәй, Ык, Мишә, Зөя, Нократ, Казансу елгалары бизи. Ул шулай ук яшел тугайларга, куе урманнарга, түгәрәк күлләргә бай.

Казан – Татарстанның башкаласы. Казанга бер мең яшь тулды. (56 сүз.)

Кыш килде.

Көз үтте. Төссез һәм соры көннәр үтеп киттеләр. Яктылык кими бара. Елгалар боз белән капланды. Кошларның күбесе җылы якка китте. Ә кайберләре бездә кышлый. Без кошларга җимлекләр ясадык. Көн саен кошларны ашаттык. Алар безгә рәхмәт әйтер. (36 сүз.)

Бирем. Янәшә тартыклар кергән сүзләрнең асларына сызарга һәм иҗекләргә аерып язарга.

**Карлар ява.**

Тышта ап-ак кар ява. Агач ботакларына мамыктай йомшак бәс куна. Бакча аеруча матур, ямьләнеп киткән. Володяга бу күренеш бик ошый. Ул чанасын алып урамга чыга. Алар, күрше малайлары белән бергәләп, бакча артындагы куаклыкта туйганчы уйнадылар. Йомшак карны тәгәрәтеп шар ясадылар. Ап-ак шар тәгәрәгән саен калыная, зурая бара. Балалар куаналар. Алар кардан ак аю, Кар бабай ясадылар. Аннан соң үзләре, читтән карап, рәхәтләнеп көлешәләр. (63 сүз.)

**Кычытканның файдасы.**

Кычытканда витамин бик күп. Кешеләр кычытканнан шулпа пешерәләр. Кычытканны, кар эремәсен өчен, кар өстенә җәяләр. Кычытканны тавыкларга турап ашатсаң, алар йомырканы күбрәк сала.

Кычытканны чапкач, без анны учмаларга бәйләдек. Ул учмаларны ферманың чормасына киптерергә элдек. Алар анда җилләп киптеләр. Кипкән кычытканны кыш көне хайваннарга ашаттык.
Кычыткан ул шундый файдалы үсемлек. (50 сүз.)
*(Атилла Расих буенча.)*
*Бирем. <u>Кычыткан</u> сүзенең килешләрен билгеләргә.*

Грамматик биремле диктант.

Мин Масрада кышны үткәрдем. Кояш карап, көннәрнең күңелен йомшартып, аны җылытып, өстенә ябынган ак юрганнарын чылатып, гөрләвекләрен агыза башлады. Тау башлары ачылып, кар астыннан чыккан урыннар яшелләнә, ташулар ага, чит җирләрдән килгән сыерчыклар сайрый, күгәрченнәр гөрли, кыш буена боегып яткан чыпчыклар да чүкелдәшә башладылар. (47 сүз.)

1. Күплектә килгән исемнәрненең асларына сызарга.
(Галиәскар Камал.Масра авылында яз башы.)
Искәрмә. Өтерләр искәртелә.
Урман сүзенә сораулар куеп, күчереп язарга.

**Авылда яз.**

Менә кыш та үтеп китте. Салкын көннәр, ачы бураннар күптән бетте инде. Кояш ешрак карый. Көннәр җылыта. Яңгырлар ява башлады. Күмәк хуҗалык эшчәннәре язгы эшләрне башлап җибәрделәр. Алар мул уңыш алу өчен көрәшә.

Ә мәктәп укучылары тырышып укыйлар. Дәресләр беткәч тә тырышып эшли алар: йорт тирәләрен җыештыралар, сыерчык оялары ясыйлар, яңа җырлар өйрәнәләр. Мәрьям белән Әгъләм кебек оста биючеләр дә бар. (61 сүз.)

*Искәрмә<u>. Мәрьям, Әгъләм</u> сүзләрен тактага язып куярга.*

*1.Фигыльләрне табып, күчереп язарга*

*2.*Беренче җөмләдә баш  һәм иярчен кисәкләрнең астына сыз, сүз төркемнәрен билгелә.

**Урманда.**

Мин Казан шәһәрендә яшим. Җәйге каникулда авылга кайтам.

Беркөнне дәү әтием мине нарат урманына алып барды. Ни генә күрмәдек  без анда! Кошлар сайравын тыңладык. Бурсык оясын күрдек. Эзләр дә бар иде. Аннары дәү әти нарат җиләге урынын тапты. Җиләге бик тәмле, әмма быел вак икән. Яңгыр азрак булгандыр. Бөрлегән дә җыйдык. Күлдә су коендык.

Урманда күргәннәремне мәктәптә малайларга да сөйләрмен әле.

Грамматик биремнәр.

I вариант.

1. Беренче җөмләдә баш  һәм иярчен кисәкләрнең астына сыз, сүз төркемнәрен билгелә.
2. Тиешле хәрефләрне куеп яз.
   Ят…мә, вәг…дә, дәр…я, шигыр…, ал…япкыч, дөн…я, көн…як.

I I вариант.

1. Беренче җөмләдә баш  һәм иярчен кисәкләрнең астына сыз, сүз төркемнәрен билгелә.

2.Тиешле хәрефләрне куеп яз.

Төн…як, табигат…, Ях…я,  юн…ле, кул…яулык, сәгат.., шагыйр….

Искәртмәле диктант.

**Урманнарны саклагыз!**

*(Кисәкчәләрнең астына сыз.)*

Кешеләргә иген үстерүдә булышкан өчен кадерле ул урман. Илгә муллык, табигатькә гүзәллек биргәне, күңелләргә хозурлык өстәгәне өчен дә яратабыз без аны.

Агачлар басуларны салкын һәм коры җилләрдән саклыйлар, җиргә дым тупларга ярдәм итәләр. Су белән җил эрозиясенә каршы да көрәшәләр алар. Иген кырларын урап ала торган полосаларның да файдасы әйтеп бетергесез.

Урмансыз як сайрар кошларга да бик ярлы була бит әле ул. Ә без һәр язның сандугачлар белән килүен яратабыз. Шуңа күрә урманнарны саклагыз! (76 сүз.)

*(Натуралист язмаларыннан.)*Сайланма диктант.

1. *Нишли? Нишләде? Нишләр? сорауларына җавап булган фигыльләрне генә сайлап язарга.*

Кырда тиздән тракторлар гөрелдәр. Артларыннан бик җитди төс белән кара каргалар калмый йөрерләр. Анда май коңгызлары кортын чүпләрләр.

Нинди бердәм үзләре! Хәттә ояларын да бер тирәгәрәк ясыйлар. Оялары без яши торган җирләрдә була. Бакча һәм урам агачларында. Безнең дус күргәнлекне беләләр.

Бу шатлыкка тагын бер куаныч өстәлде. Кара каргалар белән бер үк тирәдә күңелле сабан тургайлары күренде. Алар туган якларын сагынып кайтканнар. Язның күген, киң кырын сагынганнар. (67 сүз.)

(Гарәфи Хәсановтан.)

**Язгы урман.**

Апрельаенда көннәр озая. Авыл янындагы коры елгада кар ята, ә урманда тәүге чәчәкләр күренә, бүре курысы куаклары алсу утлар кабыза.

Чикләвек куаклары да язгы бәйрәмне башлап җибәрәләр. Алтын алкалары бигрәк матурлар. Умарта кортлры алтын алкаларга сыралар, Кызыл чәчәкләргә куналар. Тегe ал чәчәкләрне дә читләтеп узмыйлар. Хәйләкәр дә соң куаклар. Ал яки кызыл чәчәкләр – шул алтын кортлар күрсен өчен, ә алка чәчәкләр – җил тоткарлмый үтсен өчен: язгы җил чәчәк тузаннарын очыра. (69 сүз.)

*(Гарәфи Хәсәновтан.)*Бирем. Хикәядән өч гади дәрәҗәдәге сыйфат сайлап язарга һәм чагыштыру дәрәҗәсендә күрсәтергә.

**Бәяләү нормалары һәм критерийлар**

1. Эш пөхтә башкарылса, хатасы булмаган эшкә “5” ле куела. (Бер – орфографик, ике пунктуацион хата булырга мөмкин.)
2. Ике орфографик, ике пунктуацион яки бер орфографик, дүрт пунктуацион хаталы эшкә “4” куела.
3. Дүрт орфографик, дүрт пунктуацион яки өч орфографик, алты пунктуацион хаталы эшкә “3” куела.
4. Алты орфографик, биш пунктуацион яки биш орфографик, сигез пунктуацион хаталы эшкә “2” куела.